| | |
|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2024 № 296-П

Казан

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә урнашкан «III Барскоенорускино авыл җирлеге» мәдәни (археологик) мирас объектын эзләп табылган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның аерым режимын раслау турында

2002 нче елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында"гы Федераль кануны, 2005 нче елның 1 апрелендәге 60-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы Татарстан Республикасы кануны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 12 нче июлендәге “Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре " карары нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә урнашкан «III Барскоенорускино авыл җирлеге» археологик мирас объектын, әлеге боерыкның 1 нче номерлы кушымтасы нигезендә эзләп табылган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Расларга:

әлеге боерыкның 2 нче кушымтасына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә урнашкан «III Барскоенорускино авыл җирлеге» мәдәни (археологик) мирас объектының чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

әлеге боерыкның 2 нче кушымтасына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә урнашкан «III Барскоенорускино авыл җирлеге» мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен куллануның махсус режимын;

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 02 июльдәге 296-П номерлы боерыгына караган 3 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә урнашкан «III Барскоенорускино авыл җирлеге» мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен куллануның махсус режимы

Археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы археологик кыр эшләрен 2002 елның 25 нче июнендә нәшер ителгән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» Федераль закон (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән урманга бәйле җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен, башка эшләрне, археологик мирас объектының сакланышын, гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шартлары үтәлгәндә башкару мөмкинлеген күз алдында тота.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органнары биргән рөхсәт (ачык бит) нигезендә, археологик предметларны эзләү һәм табып алу максаты булган эшләрне дә үз эченә алган археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен үткәрү;

73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән археологик мирас объекты территориясе чикләрендәге урманнарны куллану масксатыннан үткәрелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашыру шарты белән, мондый эшләрне башкару проектларына, яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларына, йә уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган археологик кыр эшләрен уздыру планына нигезләнеп, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү;

археологик мирас объектын музейлаштыру чараларын үткәрү;

гражданнарның археологик мирас объектына керүен законнар нигезендә оештыру;

кипкән үләннәрен чапбу, территорияне коры-сарыдан, үзлегеннән тишелеп үскән агач һәм куаклардан, үсентеләрдән арындыру.

**2. Тыела:**

73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән археологик мирас объекты территориясе чикләрендәге урманнарны куллану масксатыннан үткәрелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән археологик мирас

объектының сакланышын тәэмин итү өлкәсендәге проектларны, йә үткәрелә торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган торгызу археологик кыр эшләрен уздыру планындагы мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча башкару

туфракны, каты һәм башка төрле көнкүреш калдыкларын, шул исәптән төзелеш калдыкларын туплау;

туфрак һәм токымнарны алу;

чүп-чар, көнкүреш калдыкларын билгеләнгән урыннардан тыш җирләргә ташлау.